# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, №3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 5 статьяны төшереп калдырырга.

2. 8 статьяның 3 абзацын төшереп калдырырга.

3. 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты компетенциясе

Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

– экологик дәүләт программаларын әзерли һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына тәкъдим итә;

– табигый байлыклардан файдаланган, пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен түләүнең дифференциацияләнгән ставкаларын законнар нигезендә билгели;

– республика күләмендә әһәмияткә ия булган табигать-тыюлык фонды территорияләрен һәм объектларын оештыру турында карарлар кабул итә;

– Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигый байлыклар өлкәсендә министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарның эшен берләштерә һәм аңа юнәлеш бирә;

– табигый байлыкларны исәпкә алуны һәм бәяләүне оештыра;

– Татарстан Республикасы милкенә кертелгән табигый байлыклардан файдалану тәртибен билгели;

– Татарстан Республикасы милкенә кертелгән аеруча кыйммәтле табигый байлыклар исемлеген һәм аларны алу тәртибен раслый;

– республика күләмендә әһәмияткә ия булган табигый байлыкларның запасларын раслый;

исп .тел.64-
4/ sak-tab

– Татарстан Республикасы милкенә кертелгән хайваннар (шул исәптән балык запаслары да) һәм үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдалануга квоталар билгели;

– Татарстан Республикасының Экология фондын барлыкка китерү һәм аннан файдалану тәртибен законнар нигезендә билгели;

– әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары арасында килеп чыккан мәсьәләләрне карау һәм хәл итү эшендә катнашу өчен вәкилләр билгеләп куя;

– әйләнә-тирә табигать мохитенең торышы һәм аны савыктыру гамәлләре турында еллык дәүләт нотыгын әзерләүне һәм таратуны оештыра;

– гражданнарга өзлексез рәвештә экологик тәрбия һәм белем бирү системасын оештыра;

– халыкны кирәкле экологик мәгълүмат белән тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигый байлыклардан файдалану өлкәсендә законнар нигезендә башка төрле вәкаләтләрне дә үтәргә мөмкин.».

4. 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. Табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары компетенциясе

1. Табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

– табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге эшчәнлеккә җитәкчелек итү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклардан файдалану мәсьәләләре буенча бердәм фәнни-техник сәясәт уздыру;

– әйләнә-тирә табигать мохитенә антропоген йогынтыларның мөмкин булган нормаларын һәм нормативларын билгеләү, барлык төр табигый байлыкларны чыгаруга, файдалануга һәм житештерүгә кертүгә фәнни нигезләнгән квоталар һәм лимитлар билгеләү, табигатьтән файдалану һәм калдыклар әйләнеше өлкәсендә лицензияләүне гамәлгә ашыру;

– әйләнә-тирә мохитне саклау, табигатьтән файдалану, экологик хәвефсезлекне тәэмин итү өлкәсендә инструктив һәм норматив-ысулый материаллар эшләү;

– экологик мониторингны оештыру;

– дәүләт экологик экспертизасын оештыру һәм уздыру;

– әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру;

– Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фондына идарә итү, Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару, табигать-тыюлык эшләрен оештыру;

334

– әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә, табигый байлыклардан файдалану һәм экологик хәвефсезлек тәэмин итү өлкәсендә халыкара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

– әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынты ясаучы объектларның эшчәнлеген чикләү, туктатып тору, туктату турында карарлар кабул итү;

– законнар нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары әйләнә–тирә табигать мохитенең торышы һәм табигый байлыкларның сакланышы өчен җаваплы булалар.».

5. 11 статьяны төшереп калдырырга.

6. 14 статьяның 1 пунктында «Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары» сүзләрен «Табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары» сүзләренә алмаштырырга.

7. 15 статьяның 4 пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«– федераль бюджет, Татарстан Республикасының Республика бюджеты, җирле бюджетлар;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«– минераль-чимал базасын торгызуга табигатьтән файдаланучылардан алынучы түләүләр;».

8. 16 статьяның 2 пунктындагы икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары һәм дәүләт идарәсенең җирле органнары тарафыннан аерым очракларда законнар нигезендә табигатьтән гомуми файдалану шартлары билгеләнергә мөмкин.».

9. 17 статьяда:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Табигатьтән комплекслы файдалану өчен лицензия (рөхсәт) табигатьтән файдаланучыга законнар нигезендә бирелә.»;

3 пунктны төшереп калдырырга.

10. 18 статьяның 2 пунктында «Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары» сүзләрен «Табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары» сүзләренә алмаштырырга.

335

11. 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«19 статья. Табигатьтән файдалануның түләүле булуы

1. Табигатьтән файдалануның түләүле булуы әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан өчен һәм башка төр йогынтылар өчен түләүдән гыйбарәт.

2. Табигый байлыклардан (җир, җир асты байлыклары, су, урман һәм бүтән үсемлекләр, хайваннар дөньясы, ял итү һәм башка табигый байлыклардан) файдаланган өчен түләүләр түбәндәгеләр өчен алына:

билгеләнгән лимит чикләрендә табигый байлыклардан файдалану хокукы өчен;

табигый байлыклардан лимиттан тыш һәм нәтиҗәсез файдаланган өчен;

табигый байлыкларны торгызуга һәм саклауга.

3. Әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан өчен һәм башка төр йогынтылар өчен түләү түбәндәгеләр өчен алына:

билгеләнгән лимитлар чикләрендә пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлаган, агызып чыгарган, калдыкларны урнаштырган һәм пычратуның башка төрләре;

билгеләнгән лимитлардан артыграк итеп пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлаган, агызып чыгарган, калдыкларны урнаштырган һәм пычратуның башка төрләре.

4. Зарарлы матдәләрне нормативлар буенча һәм нормативлардан артыграк чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган, калдыкларны урнаштырган өчен түләү предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан федераль законнар нигезендә бәхәссез тәртиптә күчерелә.».

12. 20 статьяны төшереп калдырырга.

13. 21 статьяның 2 пунктында «тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели» сүзләрен «тәртибе законнар нигезендә билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга.

14. 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«22 статья. Татарстан Республикасы Экология фонды

1. Табигатьне саклау бурычларын хәл итү, әйләнә-тирә табигать мохитендәге югалтуларны торгызу, китерелгән зарарны компенсацияләү, максатчыл экологик программаларны, проектларны һәм гамәлләрне финанслау өчен Татарстан Республикасы Экология фонды төзелә.

2. Фонд юридик зат була һәм коммерциячел булмаган оешма рәвешендә төзелә.

3. Татарстан Республикасы Экология фонды акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә барлыкка китерелә һәм тотыла.

4. Татарстан Республикасы Экология фондының акчаларын табигатьне саклау эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда файдалану тыела.

5. Фонд эшләрне финанслауны бушлай һәм кире кайтару нигезендә башкарырга хокуклы.».

336

15. 25 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әйләнә-тирә табигать мохите сыйфатының нормативлары таләпләрен бозган очракта, зарарлы матдәләрне чыгарып ташлау, агызып чыгару яисә әйләнә-тирә табигать мохитенә башка төр йогынтылар табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары күрсәтмәсе буенча чикләнергә, туктатып торылырга яисә туктатылырга мөмкин.».

16. 26 статьяда:

2 пунктны төшереп калдырырга;

3 пунктны 2 пункт дип санарга.

17. 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27 статья. Шау-шу, вибрация, магнит кырлары һәм башка зарарлы физик йогынтылар күләменең иң чик мөмкин нормативлары

Шау-шу, вибрация, магнит кырлары һәм башка зарарлы физик йогынтылар күләменең иң чик мөмкин нормативлары кешеләрнең сәламәтлеген һәм хезмәткә сәләтләрен саклап калуны, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын саклауны, тереклек өчен уңайлы әйләнә-тирә табигать мохитен саклауны тәэмин итәрлек дәрәҗәдә билгеләнә һәм законнар нигезендә раслана.».

18. 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28 статья. Радиация йогынтысы күләменең иң чик мөмкин нормативлары

Әйләнә-тирә табигать мохитендә һәм азык-төлек продуктларында радиоактив матдәләрнең хәвефсез тупланышы күләменең иң чик мөмкин нормативлары һәм халыкның радиация нурланышы күләменең иң чик мөмкин нормативлары кеше сәламәтлеге һәм генетик фонды өчен куркыныч янамаслык зурлыкларда билгеләнә һәм законнар нигезендә раслана.».

19. 29 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29 статья. Агрохимикатларны куллануның иң чик мөмкин нормалары

Минераль ашламаларны куллануның, үсемлекләрне яклау чараларын, үсеш стимуляторларын һәм башка химикатларны куллануның иң чик мөмкин нормалары туфракларда һәм азык-төлек продуктларында калучы химик матдәләр микъдарларының иң чик мөмкин нормативларын үтәүне, кеше сәламәтлеген саклауны, аның генетик фондын, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын саклауны тәэмин итәрлек дозаларда билгеләнә һәм законнар нигезендә раслана.».

20. 30 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30 статья. Азык-төлек продуктларында калучы химик матдәләр микъдарының иң чик мөмкин нормативлары

Азык-төлек продуктларында калучы химик матдәләр микъдарының иң чик мөмкин нормативлары кулланылучы һәр химик матдә буенча һәм аларның бергәләп тәэсир итүе буенча кеше сәламәтлеге өчен зарарсыз дип саналган иң минималь дозаны билгеләү юлы белән куела һәм законнар нигезендә раслана.».

21. 31 статьяның 3 пунктын төшереп калдырырга.

22. 32 статьяда «әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары» һәм «дәүләт экология экспертизасы нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

23. 33 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сулыкларны һәм су белән тәэмин итүнең башка чыганакларын, курортларны, дәвалау-савыктыру зоналарын, торак пунктларны һәм башка территорияләрне пычранудан һәм экологик экспертиза объектын реализацияләүнең бүтән төрле зарарлы йогынтыларыннан саклау өчен табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары тарафыннан санитар һәм яклау зоналарының нормативлары билгеләнә.».

24. 35 статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган кагыйдәләр» сүзләрен «законнар нигезендә расланган» сүзләренә алмаштырырга.

25. 38 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка төрле объектларны төзү урыннарын билгеләү табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнарының уңай бәяләмәсе, дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының, җирле үзидарә органнарының карарлары булганда гына законнар нигезендә башкарыла. Халыкның экологик мәнфәгатьләренә кагылучы объектларны урнаштырганда карар халык фикерен яисә референдум нәтиҗәләрен исәпкә алып кабул ителә.».

26. 39 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Экологик таләпләрне канәгатьләндерми торган проектлар расланмаска тиеш, ә аларны гамәлгә ашыру эшләре тиешле банк учреждениеләре тарафыннан финансланмый.».

27. 40 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Законда бәян ителгән таләпләр бозылганда, төзелеш эшләре, билгеләнгән җитешсезлекләр бетерелгәнче, табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-

338

эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары күрсәтмәсе нигезендә туктатып торыла.».

28. 41 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка төрле объектларны эксплуатацияләүгә тапшыру проектта каралган барлык экологик таләпләрне тулы күләмдә үтәгәндә генә, табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары вәкилләре катнашында төзелүче кабул итү комиссияләре актлары буенча гамәлгә ашырыла.».

29. 42 статьяда:

2 пунктта «Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгы» сүзләрен «табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Зарарлы матдәләрне чыгарып ташлауның һәм агызып чыгаруның, барлыкка китерүнең һәм күмүнең билгеләнгән нормативларын, зарарлы матдәләрне чыгарып ташлауга, агызып чыгаруга, күмүгә рөхсәттә каралган әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча башка шартларны һәм таләпләрне үтәмәгәндә, шулай ук кеше сәламәтлегенә зыян килү куркынычы килеп туганда, зарарлы матдәләрне чыгарып ташлау, агызып чыгару, күмү һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм халык сәламәтлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек, шулай ук предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның эшчәнлеге дә табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары тәкъдиме буенча, законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә туктатып торылырга мөмкин.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Экологик зарарлы объектлар эшчәнлегенең юнәлешен үзгәртү табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары белән килешеп башкарыла.».

30. 45 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Энергетика предприятеләрен, җайланмаларын һәм башка объектларын урнаштыру, проектлаштыру, төзү һәм алардан файдалану законнардагы таләпләр нигезендә башкарыла.».

31. 47 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«47 статья. Атом-төш материалларыннан, радиоактив матдәләрдән һәм ионлы нурланышның башка чыганакларыннан файдаланганда экологик таләпләр

1. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның урындагы затлары һәм гражданнар атом-төш материалларын, радиоактив матдәләрне һәм ионлы нурланышның бүтән чыганакларын җитештерү, саклау, транспортировкалау, файдалану, утильләштерү, аерып алу һәм күмү кагыйдәләрен үтәргә һәм табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнарына кеше сәламәтлеге һәм әйләнә-тирә табигать мохите өчен куркыныч радиация нормаларының артып китүе турында кичекмәстән хәбәр итәргә, радиация йогынтысы чыганакларын киметү һәм бетерү чараларын күрергә тиеш.

2. Радиоактив калдыкларны күмүгә рөхсәтләр законнар нигезендә табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары тарафыннан бирелә.

3. Ионлы нурланыш чыганаклары белән эш итү кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итмәгән, лицензия шартларын бозган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары күрсәтмәсе буенча законнар нигезендә ионлы нурланыш чыганакларыннан файдалану эшчәнлегенә хокуктан мәхрүм ителергә мөмкин.».

32. 48 статьяда:

2,3,4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл хуҗалыгында куллану өчен рөхсәт ителгән химик препаратларның исемлеге һәм азык-төлек продуктларында кала торган химик матдәләрнең иң чик мөмкин нормалары законнар нигезендә раслана.

3. Кеше сәламәтлегенә турыдан-туры яисә читләтеп тәэсир итәрлек йә үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларына тискәре йогынты ясарлык яңа химик матдәләрне бары тик законнарда билгеләнгән тәртиптә генә кулланырга мөмкин. Таркалмый торган һәм кеше организмына, әйләнә-тирә табигать мохитенә актив йогынты ясый торган агулы химик препаратларны куллану тыела. Сәнәгадә һәм башка хуҗалык объектларында кулланылучы химик матдәләрнең экологик зарарлы йогынтысыннан кеше сәламәтлеген саклау максатларында, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау кагыйдәләре табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары тарафыннан раслана.

4. Әйләнә-тирә табигать мохитен химик пычратып, кеше сәламәтлегенә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына куркыныч тудырырлык итеп әлеге

340

кагыйдәләрне бозганда, санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органы карары буенча тиешле химик препаратларны житештерү, саклау, ташу, куллану тыела. ».

33. 49 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынты ясаучы предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны, технологияләрне урнаштырганда, проектлаштырганда, төзегәндә, файдалануга тапшырганда һәм алардан файдаланганда табигать мохитендәге микробларның, гөмбәчекләрнең, вирусларның һәм башка төрле микроорганизмнарның, биологик матдәләрнең иң чик мөмкин концентрациясенең законнар нигезендә расланган нормативлары үтәлергә тиеш.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әйләнә-тирә табигать мохитенә биологик йогынты чыганакларын күзәтү, исәпкә алу һәм аның дәрәҗәсен тикшереп тору табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

34. 51 статьяда:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Калдыкларны туплау һәм күмү дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары буенча билгеләнә торган урыннарда табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органнары белән килешенеп башкарыла.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үтә куркыныч һәм аеруча агулы калдыкларны күмү законнар нигезендә башкарыла.».

35. 55 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гадәттән тыш экологик вәзгыять зоналарын савыктыру гамәлләрен финанслау, беренче чиратта, табигать мохитен начарайтуда, бәла-казаларда яисә һәлакәтләрдә турыдан-туры гаепле булган министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар исәбеннән, шулай ук федераль бюджетның һәм Татарстан Республикасының Республика бюджетының максатчыл акчалары исәбеннән башкарыла.».

36. 56 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Экологик бәла-каза һәм афәтләр зоналарын савыктыру гамәлләрен финанслау, беренче чиратта, табигать мохитен начарайтуда, бәла-казаларда яисә һәлакәтләрдә турыдан-туры гаепле булган министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар исәбеннән, шулай

341

ук федераль бюджетның, Татарстан Республикасының Республика бюджетының, Татарстан Республикасы Экология фондының максатчыл акчалары һәм минераль-чимал базасын торгызуга табигатьтән файдаланучыларның түләүләре исәбеннән башкарыла.».

37. 59 статьяның 6 пунктында «Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгы» сүзләрен «Табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары» сүзләренә алмаштырырга.

38. 61 статьяның 4 пунктында «Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгы» сүзләрен «Табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары» сүзләренә алмаштырырга.

39. 69 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әйләнә-тирә табигать мохитенең торышын күзәтү буенча дәүләт хезмәтен оештыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе законнар белән билгеләнә.».

40. 70 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында дәүләт экология контроле Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары һәм тиешле хокук саклау органнары тарафыннан үз компетенцияләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2 пунктның 10 абзацында «эшләрне судка җибәрү турында» сүзләрен төшереп калдырырга.

41. 71 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җитештерү контроле органнарын оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан расланган нигезләмәләр белән җайга салына.».

42. 72 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җәмәгать экология контроле һөнәр берлекләре һәм башка җәмәгать берләшмәләре, хезмәт коллективлары, гражданнар тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның максаты министрлыклар һәм ведомстволар, милек рәвешләренә һәм буйсынуларына карамастан, барлык предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, урындагы затлар һәм гражданнар тарафыннан әлеге Закон һәм федераль законнар таләпләренең үтәлешен тикшереп торудан гыйбарәт.».

342

43. 73 статьяда «әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә дәүләт органнары» сүзләрен «табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтләе органнары» сүзләренә алмаштырырга.

44. 75 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм кеше сәламәтлегенә зарарлы йогынты ясаучы эшчәнлек белән бәйле министрлыкларның һәм ведомстволарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре, урындагы бүтән затлары һәм белгечләр, гражданнар кирәкле экологик әзерлеккә ия булырга тиеш, ул хезмәткәрләрне урындагы эшкә билгеләгәндә, аттестацияләгәндә һәм кабат аттестацияләгәндә исәпкә алына.».

2 пунктны төшереп калдырырга.

3 пунктны 2 пункт дип санарга.

45. 81 статьяны төшереп калдырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 июне
№ 899